ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.10.2024 ел Баулы шәһәре №126

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 13 декабрендәге
233 номерлы «2024 елга Баулы
муниципаль районы халкы өчен
торак-коммуналь хезмәтләргә
тарифлар турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2024 елның 28 августындагы 04-04/11359 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 13 декабрендәге 233 номерлы «2024 елга Баулы муниципаль районы халкы өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен» карарына 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 13 декабрендәге
233 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН
1-нче номерлы кушымта

СОЦИАЛЬ НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫНА НАЕМ ШАРТНАМӘЛӘРЕ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯЛЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН, ШУЛАЙ УК КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТ БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ЫСУЛЫН САЙЛАУ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН ҺӘМ ГОМУМИ ҖЫЕЛЫШТА ТОРАК УРЫННАРНЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТМӘГӘН ТОРАК УРЫННАР МИЛЕКЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ТОРАК УРЫННЫ КАРАП ТОТУ ҺӘМ РЕМОНТЛАУ ӨЧЕН
ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2024 елның 1 гыйнварыннан | 2024 елның 1 июленнән |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 3,10 | 3,25 |
| 2. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 1,44 | 1,50 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 2,92 | 3,04 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территорияләрен төзекләндерү, шулардан:<br>- төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;<br>- вентиляция каналларына техник - | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 3,85<br><br>0,56<br><br>0,34 | 4,01<br><br>0,56<br><br>0,34 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Инженерлык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шул исәптән:<br>- йорт эчендәге сүүткәргеч-канализация челтәрләре;<br>- йорт эчендәге үзәк җылыту;<br>- йорт эчендәге кайнар су челтәрләре<br>- узелларга техник хезмәт күрсәтү<br>-җылылык энергиясен исәпкә алу | торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 7,0<br>2,74<br>1,44<br>0,95<br>1,87 | 7,21<br>2,81<br>1,51<br>0,95<br>1,94 |
| 6. | Муниципаль торак фонды өчен сыек калдыкларны чыгару | торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 29,6 | 30,49 |
| 7. | Йорт эчендәге газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтү һәм аны тәртиптә тоту | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 0,20 | 0,28 |
| 8. | Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны тәртиптә тоту | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 1,33 | 1,40 |
| 9. | Дератизация (дезинфекция) | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | 0,15 | 0,15 |
| 10. | Йорт эчендәге газ җиһазына техник диагностика ясау (түләү исәпләү диагностика ясау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | бер айга торак урынның гомуми мәйданының кв. м. | - | 0,70* |

* МКД өчен, газүткәргеч эксплуатациягә кертелүгә 30 ел узган.